ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОГДАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

БОГДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Рус
Богдашкинос
ы ав.

БОЕРЫК

28.01.2022

№ 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль
районы Богдашкино авыл җирлегендә
гарантияле исемлек нигезендә җирләү
хезмәтләренең кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2нче кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 1 февралендәге 5нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://nurlat.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Богдашкино авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Л. Михайлова

Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 4011,67 |
| 3. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1448,65 |
| 4. | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 1504,36 |
| | Барлыгы | 6964,68 |

Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Мәетне кәфенләү (төрү) | 1337,91 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 2668,19 |
| 4. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1448,65 |
| 5. | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 1509,93 |
| | Барлыгы | 6964,68 |